РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ЕВЛАШТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422075, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Евлаштау, ул.Ш. Бариева, 23
тел. (84362) 46-8-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯВЛАШТАУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422075, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Явлаштау авылы, Ш. Бариев урамы, 23 нче йорт
тел. (84362) 46-8-49

e-mail: Evlash.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

18.10.2023 | №21

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Явлаштау авыл җирлеге Советының
31.01.2011 №3 карары белән расланган Явлаштау
авыл җирлегендә бюджет процессы
турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 31 нче январендәге №3 карары белән расланган Явлаштау авыл җирлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 нче маддәнең 2 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирлек бюджетына Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарына ярашлы рәвештә җирлекнең вәкиллекле органнары билгеләгән җирле салымнардан салым керемнәре кертелә.

1.2. 8 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек бюджетына федераль салымнардан һәм җыемнардан салым керемнәре, шул исәптән Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм Россия Федерациясенең Бюджет кодексы нигезендә махсус салым режимнарында каралган салымнар кертелә.

1.3. 9 нчы статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9 статья. Торак пункт бюджетының салым булмаган керемнәре.

1. Торак пункт бюджетының салым булмаган керемнәре Россия Федерациясе Бюджет кодексының 41, 42, 46, 58, 63 һәм 63.1 статьяларына туры китереп формалаштырыла.»;

1.4.14 нче статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"14 нче статья. Муниципаль (дәүләт) хезмәтләр күрсәтүгә (эшләрне башкаруга) бюджет ассигнованиеләре.

Муниципаль (дәүләт) хезмәтләр күрсәтүгә (эшләрне башкаруга) бюджет ассигнованиеләренә:

- казна учреждениеләре функцияләрен үтәүне тәэмин итү, шул исәптән физик һәм (яки) юридик затларга муниципаль (дәүләт) хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) буенча;

- бюджет һәм автоном учреждениеләргә субсидияләр бирү, шул исәптән муниципаль биремне үтәүне финанс тәэмин итүгә субсидияләр бирү;

- муниципаль учреждениеләр булмаган коммерцияле булмаган оешмаларга, шул исәптән әлеге оешмалар тарафыннан күрсәтелгән дәүләт муниципаль (дәүләт) хезмәтләрен күрсәтүгә (эшләрне башкаруга) физик һәм (яки) юридик затларга субсидияләр бирү;

- дәүләт муниципаль милек объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру;

- муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу (казна учреждениесе функцияләрен үтәүне тәэмин итү өчен бюджет ассигнованиеләреннән һәм казна учреждениеләренең муниципаль милек объектларына бюджет ассигнованиеләрен гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләреннән тыш), шул исәптән юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга субсидияләр бирү максатларында - социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказын үтәүне финанс тәэмин итү максатларында товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Явлаштау авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/evlashtay адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Явлаштау авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Нуриев